ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.12.2021 г. Заинск № 801

**«2022-2024 елларга Зәй муниципаль районында хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау программасы» муниципаль программасын раслау турында**

Хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру максатында, «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» 1997 елның 10 декабрендәге 1417 номерлы Татарстан Республикасы Законы, «2014-2025 елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 09 августындагы 553 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә «2014-2025 елларга Татарстан Республикасында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру максатында, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «2022-2024 елларга Зәй муниципаль районында хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау программасы» муниципаль программасын кушымта нигезендә расларга.
2. Оешмалар, учреждениеләр, предприятиеләр җитәкчеләренә, милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, әлеге Программаны гамәлгә ашыру чараларын күрергә тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында: http://zainsk.tatarstan.ru урнаштырырга.
4. Карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Р.М. Хаҗиповка йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э.Галеев**

И.В.Гобәйдулина
(85558)3-37-47

**2022 - 2024 елларга Зәй муниципаль районында хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау программасы**

**ПАСПОРТЫ**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2022-2024 елларга Зәй муниципаль районында хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау программасы |
| Муниципаль заказчы(координатор) | Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны төп эшләүче | Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының ТКХ, төзелеш, транспорт, энергетика, элемтә һәм юл хуҗалыгы бүлеге |
| Программаны үтәүчеләр | Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты, Хезмәтне саклау буенча координация советы, РФ ФСС ГУ-РО ТР буенча 15 нче филиалы(Дәүләт учреждениесе - Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлекчәсе),Роспотребнадзорның ТР (Татарстан) буенча идарәсенең Әлмәт, Зәй, Лениногорск районнарында территориаль бүлеге,район предприятиеләре, учреждениеләре, оешмалары,предприятиеләрнең профсоюз оешмалары,дәүләт күзәтчелеге органнары,Зәй муниципаль районы мәгариф учреждениеләре,өстәмә һөнәри белем бирү учреждениеләре |
| Программаны эшләү өчен нигез | Россия Федерациясе Хезмәт кодексы. «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында»1997 елның 10 декабрендәге 1417 номерлы Татарстан Республикасы законы |

| | |
|---|---|
| Программаның максаты һәм бурычлары | Хезмәтне саклауга һәм хезмәт шартларына куркынычсызлык һәм гигиена таләпләренә җавап бирә торган конституция гарантияләрен тәэмин итү, производствода җәрәхәтләнү һәм һөнәри авырулар санын киметү;<br>Район территориясендә урнашкан оешмалар хезмәткәрләренең һөнәри хәвефлелеген киметү максатларында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту;<br>Эш бирүченең сәламәт һәм имин хезмәт шартлары булдыруын тәэмин итүче һәм стимуллаштыручы икътисадый һәм оештыру принципларын формалаштыру;<br>Хезмәтне саклау белән идарә итүнең дәүләт системасын үстерү;<br>Производствода имгәнүләрне, һөнәри авыруларны киметү;<br>Район оешмаларында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклау торышын яхшырту;<br>Хезмәтне саклауны мәгълүмати һәм норматив тәэмин итүне сыйфат ягыннан яхшырту. |
| Программаны тормышка ашыру вакыты һәм этаплары | 2022-2024 еллар |
| Финанслау чыганаклары, елларга бүлеп, чыганакларын күрсәтеп | Муниципаль программаны финанслауның гомуми күләме 30,0 мең сум тәшкил итә,шул исәптән елларга бүлеп:<br>2022 ел – 10,0 мең сум;<br>2023 ел – 10,0 мең сум;<br>2024 ел – 10,0мең сум;<br>Программаны финанслау күләме фаразланган характерда һәм ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш. |
| Ярдәмче программалар исемлеге | - Хезмәт шартларын яхшырту чаралары<br>-Хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау проблемасының характеристикасы һәм аны программа ысулы белән хәл итүнең нигезләнүе<br>-Производствода имгәнү<br>- 2022-2024 елларда эш урынында имгәнү күрсәткечләре<br>-Программаның максатлары һәм төп бурычлары<br>- Муниципаль программаның төп максатлары, бурычлары<br>-Программаны тормышка ашыру вакыты<br>-Муниципаль программаны ресурслар белән |

| | |
|---|---|
| | тәэмин итүне нигезләү<br>-Муниципаль программаны тормышка ашыру механизмы<br>-Программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген бәяләү |
| Елларга бүлеп һәм чыганакларын күрсәтеп,финанслау күләмнәре | Район предприятиеләренең үз акчалары |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре (нәтиҗәлелек күрсәткечләре) | 1.Программа чараларын тормышка ашыру 2024 елга мөмкинлек бирәчәк:<br>-производствода зыян күрүчеләр санын 1000 эшчегә исәпләп киметү–1000 эшләүчегә 0 кешегә кадәр;<br>-хезмәтне саклау буенча укулар узган җитәкчеләр һәм белгечләрнең санын 1000 эшчегә 20гә кадәр җиткерү;<br>- зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартлары белән эшләүдә мәшгуль хезмәткәрләрнең чагыштырма санын районда эшләүчеләрнең гомуми санына карата 25кә кадәр киметү;<br>- районда хезмәт шартлары махсус бәяләгән эш урыннарында эшләүче хезмәткәрләрнең чагыштырма санын районда эшләүчеләрнең гомуми санынннан 98% ка кадәр арттыру.<br>2. Социаль эффект:<br>- начар хезмәт шартларында эшләүче хезмәткәрләр санын киметү;<br>- производство травматизмы һәм һөнәри авырулар санын киметү;<br>- хезмәткәрләрне зарарлы һәм куркыныч эш урыны факторларыннан саклау дәрәҗәсен күтәрү;<br>- хезмәткәрләргә куркынычсыз хезмәт шартларын тәэмин итүгә конституциячел хокукны гамәлгә ашыру.<br>3. Икътисадый эффект:<br>-производствода бәхетсезлек очракларыннан зыян күргән хезмәткәрләрнең сәламәтлеген торгызуга матди чыгымнарны, авырулар, һөнәри авырулар белән бәйле җитештерү чыгымнарын киметү;<br>- производствода бәхетсезлек очраклары һәм һөнәри авырулар нәтиҗәсендә хезмәткәрләргә китерелгән зыянны каплауга чыгымнарны киметү; |

| | |
|---|---|
| | - зарарлы һәм куркыныч хезмәт шартларында эшләгән өчен ташламалар һәм компенсацияләр бирүгә чыгымнарны киметү;<br>- производствода имгәнү яки һөнәри авыру аркасында инвалидлык дәрәҗәсен һәм сәламәтлек саклау өлкәсендә чыгымнарны киметү;<br>- эш вакытын югалтуларны киметү хисабына хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру. |

## I. Хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау проблемасының характеристикасы һәм аны программа ысулы белән хәл итүнең нигезләнүе

Хезмәтне саклау хезмәт эшчәнлеге барышында гражданнарның гомерен һәм сәламәтлеген саклауның мөһим шарты булып тора. Хезмәтне саклау буенча дәүләт идарәсе хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт функцияләрен берләштерү процессында гамәлгә ашырыла. Хезмәтне саклау буенча дәүләт идарәсе системасы хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга, хезмәт барышында кешенең иминлеген, сәламәтлеген һәм эшкә сәләтлелеген тәэмин итү буенча хокукый, социаль-икътисадый, оештыру-техник, санитария-гигиена, дәвалау-профилактика һәм башка чараларны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән.

Программаны Зәй муниципаль районында муниципаль берәмлек дәрәҗәсендә эшләү һәм гамәлгә ашыру кирәклеген билгеләүче мөһим факторбулып халыкның тормыш сыйфатын яхшырту һәм сәламәтлеген һәм эшкә сәләтен саклау өлешендә әлеге проблеманың социаль әһәмияте тора.

Программа хезмәт эшчәнлеге процессында хезмәткәрләрнең гомерен һәм сәламәтлеген саклау таләпләренә җавап бирә торган хезмәт шартларын тәэмин итү, эшләүчеләрнең дәүләт гарантияләрен һәм хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләрен гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән.

Эш урыннарында сәламәт һәм имин хезмәт шартлары тудыру җәмгыятьнең социаль-икътисадый иминлегенә зур йогынты ясый.

### Эш урынында имгәнүләр

2021 елда Зәй муниципаль районында "Татнефтедор" ҖЧҖнең Зәй автомобиль юллар идарәсендә һәм "Татэнерго" АҖ Зәй ГРЭСыфилиалында бәхетсезлек очраклары булды (берсе үлем очрагы, икенчесе - авыр хәлгә килү).

Динамика шуны күрсәтә:

-2019 елда өч бәхетсезлек очрагы (берсе - үлем очрагы һәм икесе - авыр очрак);

-2020 елда - бер авыр бәхетсез очрагы.

Зәй муниципаль районында соңгы елларда, үткән еллар белән чагыштырганда, эш урынында имгәнүләр саны кимү күзәтелә.

**2019-2021 елларда эш урынында имгәнүләр күрсәткечләре**

| | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
|---|---|---|---|
| үлем белән тәмамлану | 1 | - | 1 |
| авыр тәмамлану белән | 2 | 1 | 1 |
| җиңелчә имгәнү очрагы | - | - | - |

Эш урыннарында имгәнүләрнең төп сәбәпләре - хезмәтне саклауның гомуми таләпләренә өйрәтү буенча эшләнгән программаларның булмавы, кереш инструктаж һәм эш урынында инструктаж үткәрелмәү, эш урыннарында хезмәткәрләр белән стажировка уздырылмау.

Икътисадый эшчәнлекнең төрле өлкәләрендә производство травмаларының гомуми сәбәпләре булып тора:

- технологик җиһазларның, машиналарның һәм механизмнарның тузуы һәм искерүе;

- эш бирүченең турыдан-туры эш башкаручылар өчен куркынычсыз хезмәт шартларын тәэмин итү буенча кирәкле оештыру чараларын үтәмәве;

- җитәкчеләр тарафыннан куркынычсыз җитештерүгә нәтиҗәле контроль булмау;

- куркынычсыз эш өчен җаваплы затларны билгеләмәү;

-кирәкле технологик документацияне эшләмичә эшләр башкару;

- уку-укыту һәм хезмәтне саклау буенча белемнәрне тикшерү, хезмәтне саклау буенча инструктажлар уздыруның канәгатьләнерлек булмавы;

- хезмәт һәм җитештерү дисциплинасы кимү.

Хезмәтне саклау өчен бүлеп бирелгән суммадан хезмәткәрләрнең иминлеге, аларның тормышы һәм сәламәтлеге турыдан-туры бәйле. Хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту чараларын финанслау Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 226 статьясы нигезендә эш бирүченең бурычы булып тора. Әмма үз хезмәткәрләренең иминлеге өчен социаль җаваплылыгы түбән дәрәҗәдә булган җитәкчеләр бу мәсьәләгә тиешле игътибар бирмиләр.Хезмәтне саклау чараларына чыгымнар предприятие җитәкчеләренең хезмәтне саклауга һәм үз хезмәткәрләренең гомерен һәм сәламәтлеген яклауга мөнәсәбәтендә, димәк, хезмәтне саклау белән идарә итүнең гамәлдәге системасының нәтиҗәлелеге индикаторы булып тора.

Статистик тикшерүгә авыл хуҗалыгы, аучылык һәм урман хуҗалыгы, файдалы казылмалар чыгару, эшкәртү производстволарында, электр

энергиясе, газ һәм су җитештерү һәм бүлү, төзелеш, транспорт һәм элемтә буенча эшчәнлек алып баручы предприятиеләр җәлеп ителде. Хезмәт шартларының торышы турында төп күрсәткечләр-хезмәт шартларын махсус бәяләү нәтиҗәләре, оешмаларда эш урыннарын санитар-техник паспортлаштыру.

Куркынычсыз хезмәт шартлары тудыру, травматизмны булдырмау оешкан мәгълүмат белән тәэмин итүгә һәм хезмәтне саклауны пропагандалауга бәйле, ул кешеләрнең тормыш позициясенә тәэсир итүче эмоциональ халәтне формалаштыру, производствода тормыш һәм сәламәтлекне саклау белән бәйле төрле хәлләрдә үз-үзеңне тоту максатларында фән һәм техниканың соңгы казанышлары турында мәгълүматны, идеяләрне таратуга юнәлтелгән.Хезмәтне саклау мәсьәләләрен пропагандалау ысулларының күптөрлелеге шартларында мондый пропаганданың ахыргы максаты бер - эшчеләрдә эшләрне имин уздыру таләпләрен үтәү кирәклеген, хезмәткәрләрдә куркынычсыз эшкә ярдәм итүче сыйфатларны көчәйтү, куркынычсызлык мәсьәләләренә карата уңай мөнәсәбәт тудыру.Статистик мәгълүматларга анализ күрсәткәнчә, оештыру сәбәпләре буенча травматизмнар техник сәбәпләр аркасында булган бәхетсезлек очраклары саныннан артып китә.

Массакүләм мәгълүмат чараларында хезмәтне саклау мәсьәләләрен яктырту хезмәт иминлеген пропагандалауның мөһим чарасы булып тора.

Хезмәтне саклау мәсьәләләрен мәгълүмати тәэмин итү һәм пропагандалау чаралары хезмәтне саклау таләпләрен үтәгән өчен эшләүчеләрнең җаваплылыгын арттыруга ярдәм итә, бу җитештерүдә гомуми травматизмны киметүгә китерә.

Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыруда уңай нәтиҗәләргә ирешүнең нәтиҗәле ысулы - программа-максатчан планлаштыру методын куллану, ул бюджетның чикләнгән ресурсларын оптимальләштерергә, хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттырырга, хезмәтне саклау өлкәсендә куелган бурычларны хәл итү өчен аларның көчләрен берләштерергә мөмкинлек бирә.

Хезмәтне саклау белән бәйле факттагы вәзгыять хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау проблемасына программ якын килү зарурлыгын, хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру кирәклеген күрсәтә.

Программа бәхетсезлек очракларын кисәтү һәм хезмәткәрләрнең сәламәтлегенә зыян китерү өлешендә хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләрен тормышка ашыруга, хезмәт эшчәнлеге процессында хезмәткәрләрнең тормышын һәм сәламәтлеген саклау таләпләренә җавап бирә торган хезмәт шартларын тәэмин итүгә, хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау өлкәсендә эшләүче халыкны хокукый яклау өлкәсендә дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

## II. Программаның төп максатлары һәм бурычлары

Программаның төп максаты-Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан оешмалар хезмәткәрләренең һөнәри куркынычларын киметү максатыннан хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту.

Куелган максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:

-производствода бәхетсезлек очраклары һәм һөнәри авырулар куркынычын киметү;

- укытуның заманча технологияләре нигезендә хезмәтне саклау хезмәткәрләрен өзлексез әзерләү;

- эш урыннарында хезмәт шартларының сыйфатын күтәрү;

- булдырмый калырдай сәбәпләрдән үлем-китемнәрне киметү;

- эшләүче халыкның сәламәтлеген яхшырту:

- хезмәтне саклауны мәгълүмати тәэмин итү һәм пропагандалау һ.б.

Программаның максатына ирешү һәм бурычларын хәл итү түбәндәге максатчан индикаторлар (күрсәткечләр) белән бәяләнә.

## III.Программаны тормышка ашыру вакыты

Программа, алдагы елларда да дәвам ителәчәген исәпкә алып, 2022 – 2024 елларга исәпләнгән.

## Чараларны үтәүдә катнашучылар

- Зәй муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координацион советы
- предприятиеләрнең профсоюз оешмалары
- социаль иминият фонды, дәүләт күзәтчелеге органнары
- Зәй муниципаль районы мәгариф учреждениеләре
- өстәмә һөнәри белем бирү учреждениеләре

## IV.Муниципаль программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Программаны финанслау чыганагы-Зәй муниципаль районы предприятиеләре һәм оешмаларының үз акчалары.

## V.Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары

Программаны финанслауның гомуми күләме-30,0 мең сум, шул исәптән:

- Зәй муниципаль районы бюджеты акчасы-30,0 мең сум;

Программаны финанслау чыганагы - Зәй муниципаль районы бюджеты һәм бюджеттан тыш акчалар.

Программаны финанслау күләмнәре фаразланган характерда, җирле бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

## VI.Муниципаль программаны гамәлгә ашыру механизмы

Программаны гамәлгә ашыру белән идарә итүне муниципаль заказчы - Программаның координаторы - Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты гамәлгә ашыра.

Муниципаль заказчы - программаның координаторы:

- программа чаралары исемлеген әзерләү һәм төгәлләштерү эшчәнлеген, программа чаралары буенча чыгымнарны һәм программаны гамәлгә ашыру механизмын җайга сала;

- максатчан индикаторлар һәм программаның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре исемлеген ачыклый;

- программаны гамәлгә ашыру барышы турында хисап алып бара һәм аны тиешле министрлыкларга һәм ведомстволарга билгеләнгән тәртиптә җибәрә.

Программаны финанслау тәртибе һәм аны үтәү чыгымнарын исәпкә алу Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив документлары белән билгеләнә.

Программаны гамәлгә ашыруның барышын контрольдә тоту Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары тарафыннан гамәлгә ашырыла, ул программаны гамәлгә ашыру белән идарә итүне оештыруның формаларын һәм ысулларын мөстәкыйль билгели.

## VII. Программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаны гамәлгә ашырудан социаль файда түбәндәгечә чагыла:

- уңайсыз хезмәт шартларында эшләүче хезмәткәрләр саны кимү;

-эш урынында имгәнүләр һәм һөнәри авырулар саны кимү;

-зыянлы һәм куркыныч җитештерү факторлары йогынтысыннан хезмәткәрләрнең яклану дәрәҗәсен арту;

-хезмәткәрләргә имин хезмәт шартлары тәэмин итүгә конституциячел хокукны гамәлгә ашыру.

Икътисадый нәтиҗә түбәндәге күрсәткечләр белән бәяләнә:

-производствода бәхетсезлек очракларыннан зыян күргән хезмәткәрләрнең сәламәтлеген торгызуга, производство белән бәйле авыруларны, һөнәри авыруларны дәвалау чыгымнарын киметү;

-производствода бәхетсезлек очраклары һәм һөнәри авырулар нәтиҗәсендә хезмәткәрләргә китерелгән зыянны каплауга чыгымнарны киметү;

- зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартларында эшләү өчен гарантияләр һәм компенсацияләр бирүгә чыгымнарны киметү;

-производствода гарипләнү яки һөнәри авыру һәм сәламәтлек саклау өлкәсендәге чыгымнар нәтиҗәсендә инвалидлык күрсәткечен киметү;

-Эш вакыты югалтуларын кыскарту исәбенә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру.

Социаль-икътисадый нәтиҗә Зәй муниципаль районы предприятиеләренең һәм оешмаларының тормыш дәрәҗәсен, хезмәтне саклау белән идарә итү функциясен бәяләү индикаторларының нәтиҗәле күрсәткечләренә ирешүдә чагыла:

| Индикаторларның исеме | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
|---|---|---|---|
| 1. Хезмәтне саклау чараларына чыгымнар бер кешегә исәпләгәндә (сум) | 25.000 | 25.000 | 25.000 |
| 2.Производствода бәхетсезлек очракларыннан зыян күргән кешеләр саны 1 000 эшчегә исәпләнгәндә | 0 | 0 | 0 |
| 3. 1000 хезмәткәргә исәпләгәндә җитәкчеләр һәм белгечләрнең хезмәтне саклау буенча укулар узуы күрсәткече,% | 30-40 | 30-50 | 30-50 |
| 4.Зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартларында эшләүче хезмәткәрләрнең чагыштырма күрсәткече, % | 50-60 | 50-50 | 50-50 |

Программаны гамәлгә ашырудан икътисадый файда шулай ук эш бирүчеләр тарафыннан хезмәтне саклау чараларына бүлеп бирелгән акчаларны арттыруда чагылачак, бу эшләүчеләрнең куркынычсызлыгын арттыруны тәэмин итәчәк.

Программаны тормышка ашыру эш бирүчеләрнең сәламәт һәм имин хезмәт шартлары булдыру буенча эшчәнлегенең оештыру һәм икътисадый принципларын формалаштырырга мөмкинлек бирәчәк. Шулай итеп, программаны тормышка ашыруга бүлеп бирелә торган акчалар предприятиеләрнең хезмәтне саклау чараларын тормышка ашыруга кертемнәрен икътисади яктан арттырачак.

Зәй муниципаль районында 2022-2024 елларга хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау муниципаль программасына 1 нче кушымта

**Зәй муниципаль районында 2022-2024 елларга хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау программасын тормышка ашыру буенча чаралар**

| № п/п | Чараларның исеме | Финанслау чыганаклары | Үтәлү вакыты, елларын күрсәтеп | Чыгымнарны финанслау, мең сум. | | | | Башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Барысы | 2022 | 2023 | 2024 | |
| | | 1. Хезмәтне саклауны хокукый һәм норматив тәэмин итү | | | | | | |
| 1.1. | Хезмәтне саклау өлкәсендә хокукый актларны камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү | | 2022 -2024 еллар | - | - | - | - | Зәй муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координация советы |
| | | 2. Хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны оештыру һәм техник яктан тәэмин итү | | | | | | |
| 2.1. | Хезмәтне саклау буенча норматив күрсәтмә документларны сатып алу һәм пропагандалау | Җирле бюджет акчалары | 2022-2024 | 30,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | Башкарма комитет, Зәй муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координация советы |
| 2.2. | Россия Федерациясе Хезмәт Кодексының 217 статьясы нигезендә предприятиеләрдә хезмәтне саклау хезмәте булдыруны тәэмин итәргә | Предприятие һәм оешмалар акчалары | Бөтен чорда | - | - | - | - | Зәй муниципаль районы оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре (килешү буенча), Зәй муниципаль районы предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре профсоюз оешмалары (килешү буенча) |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.3. | «Бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан хезмәткәрләрне мәҗбүри социаль иминиятләштерү турында" 1998 елның 24 июлендәге 125-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законын гамәлгә ашыру буенча чаралар эшләү | Социаль иминият фонды | 2022 -2024 еллар | - | - | - | - | Социаль иминият фонды, Зәй муниципаль районы оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 2.4. | Хезмәтне саклау кабинетлары һәм почмаклар булдыру һәм җиһазлау | Предприятие һәм оешмалар акчалары | Бөтен чорда | - | - | - | - | Зәй муниципаль районы оешмалары, учреждениеләре (килештерү буенча) |
| 2.5. | Норматив срокларын эшләгән һәм хезмәтне саклау таләпләренә туры килми торган җиһазларны модернизацияләү, реконструкцияләү, эксплуатацияләүдән чыгару | Предприятиеләр акчалары | 2022 -2024 еллар | - | - | - | - | Зәй муниципаль районы оешмалары, учреждениеләре (килештерү буенча) |
| 2.5. | Хезмәтне саклау буенча инструкцияләрне яңадан карау | Предприятиеләр акчалары | Гамәлдә булу вакыты чыкканчы | - | - | - | - | Зәй муниципаль районы оешмалары, учреждениеләре (килештерү буенча) |
| 2.6. | Хезмәтне саклау һәм куркынычсыз хезмәт шартлары буенча күрсәтмә әсбаплар белән тәэмин итү | Предприятиеләр акчалары | Ел саен | - | - | - | - | Зәй муниципаль районы оешмалары, учреждениеләре (килештерү буенча) |
| 2.7. | Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы хезмәтне саклау буенча координацион Совет утырышларын үткәрү | | Айга 2 тапкыр һәм кирәк булган саен | - | - | - | - | Зәй муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координация советы |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.8. | Зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә хатын-кызларның хезмәтен чикләү буенча чаралар эшләү | Предприятиеләр акчалары | 2022 -2024 еллар | - | - | - | - | Зәй муниципаль районы оешмалары, учреждениеләре (килештерү буенча) |
| 2.9. | Массакүләм мәгълүмат чараларында шәһәр һәм район предприятиеләрендә хезмәт шартларының һәм хезмәтне саклауның торышын, производствода имгәнүләрнең һәм һөнәри авыруларның торышын яктырту. | | 2022 -2024 еллар | - | - | - | - | Зәй муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координация советы |
| 2.10 | Бөтендөнья хезмәтне саклау көне кысаларында чаралар әзерләү һәм үткәрү (28 апрель) | Предприятиеләр акчалары | Апрель, ел саен | - | - | - | - | Зәй муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координация советы, ЗМР оешмалары, учреждениеләре җитәкчеләре (килешү буенча), предприятиеләрнең, оешмаларның, учреждениеләрнең һөнәр берлекләре оешмалары (килешү буенча) |
| 3. Хезмәтне саклау буенча дәүләт идарәсе системасын үстерү | | | | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.1. | Хезмәткәрләрне, шул исәптән оешма җитәкчеләрен, шулай ук эш бирүчеләрне, индивидуаль эшкуарларны, хезмәтне саклау таләпләрен белүләрен, шулай ук производствода зыян күрүчеләргә беренче ярдәм күрсәтү буенча укулар, хезмәтне саклау буенча инструктаж, эш урынында стажировка үткәрүне билгеләнгән тәртиптә оештыру | Предприятиеләр, социаль иминият фонды акчалары | даими | - | - | - | - | Зәй муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координация советы, ЗМР оешмалары, учреждениеләре җитәкчеләре (килешү буенча), предприятиеләрнең, оешмаларның, учреждениеләрнең һөнәр берлекләре оешмалары (килешү буенча) |
| 3.2. | Хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрүне оештыру һәм хезмәтне саклау буенча эшләрне оештыруның хезмәтне саклау буенча дәүләт норматив таләпләренә туры килүен раслау | Предприятиеләр, социаль иминият фонды акчалары | даими | - | - | - | - | Зәй муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координация советы, хезмәт шартлары буенча эш урыннарын аттестацияләү эшчәнлегенә лицензиясе булган оешмалар (килешү буенча) |
| 3.3. | Район территориясендә эшчәнлек алып баручы эш бирүчеләрдән хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау торышы турында мәгълүмат җыю һәм эшкәртүне оештыру | | даими | - | - | - | - | Зәй муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координация советы |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.4. | Зәй муниципаль районы предприятиеләрендә, оешмаларында, учреждениеләрендә производство травмалары, һөнәри авырулар торышы мониторингын тормышка ашыру | | II яртыеллык, ел саен | - | - | - | - | Зәй муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координация советы, дәүләт статистикасының Зәй бүлеге (килешү буенча), Россия кулланучылар күзәтчелегенең Зәй районындагы территориаль бүлеге (килешү буенча) |
| 3.5. | Зәй муниципаль районы предприятиеләрендә хезмәтне саклауның торышы, производство травмаларының, һөнәри авырулар санының торышы турында аналитик белешмә әзерләү | | ел саен | - | - | - | - | Зәй муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координация советы, дәүләт статистикасының Зәй бүлеге (килешү буенча), Россия кулланучылар күзәтчелегенең Зәй районындагы территориаль бүлеге (килешү буенча) |
| 3.6. | Зәй муниципаль районы предприятиеләрендә, оешмаларында һәм учреждениеләрендә хезмәт шартларының һәм хезмәтне саклауның торышы буенча уртак комплексly тикшерүләр үткәрүдә катнашу | | Бөтен чорда | - | - | - | - | Зәй муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координация советы, Россия кулланучылар күзәтчелегенең Зәй районындагы территориаль бүлеге, Зәй муниципаль районы предприятиеләренең, учреждениеләренең һөнәр оешмалары (килешү буенча) |
| **4. Дәвалау-профилактика һәм тернәкләндерү чаралары** | | | | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4.1. | РФ Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 12.04.2011 ел, №302н боерыгы нигезендә, хезмәткәрләргә башлангыч һәм вакытлы медицина тикшерүләрен үткәрүне оештыру | Предприятиеләр, социаль иминият фонды акчалары | 2022 – 2024 еллар | - | - | - | - | Зәй муниципаль районы оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 5. Предприятиеләрдә хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау | | | | | | | | |
| 5.1. | Зәй муниципаль районының һәр предприятиесе (учреждениесе) буенча 2022-2024 елларга хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау программаларын эшләү | Оешмалар һәм учреждениеләр акчалары | 2021 елның 1 яртысы | - | - | - | - | Зәй муниципаль районы оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 5.2. | Хезмәтне саклау турындагы законнарны үтәү мәсьәләләре буенча 18 яшькә кадәрге хатын-кызларның хезмәтен куллану һәм хезмәтне саклау белән бәйле предприятиеләрнең комплекслы максатчан тикшерүләрен үткәрүдә катнашу | | Бөтен чорда | - | - | - | - | Зәй муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координация советы |
| 5.3. | Хатын-кызлар өчен гигиена һәм көнкүреш бүлмәләрен ремонтлау һәм җиһазлау | Оешмалар һәм учреждениеләр акчалары | аерым планнар, графиклар буенча | - | - | - | - | Зәй муниципаль районы оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 6. Хезмәтне саклау өлкәсендә социаль партнерлыкны камилләштерү | | | | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6.1. | Оешмаларда һәм учреждениеләрдә хезмәтне саклау буенча күмәк шартнамәләр һәм чаралар планнары проектларын әзерләүне методик һәм оештыру ягыннан тәэмин итү | | Бөтен чорда | - | - | - | - | Зәй муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координация советы |
| 7. Хезмәтне саклау, мәгълүмати тәэмин итү һәм хезмәтне саклауны пропагандалау мәсьәләләре буенча хезмәткәрләрне, җитәкчеләрне һәм белгечләрне укыту | | | | | | | | |
| 7.1. | Хезмәтне саклау буенча җитәкчеләрне, белгечләрне укытуны оештыру | Оешмалар (учреждениеләр) акчалары | Бөтен чорда | - | - | - | - | Зәй муниципаль районы оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 7.2 | Хезмәтне саклау буенча норматив күрсәтмә документация, махсус әдәбият, уку һәм күрсәтмә пособиеләр сатып алу | Оешмалар (учреждениеләр) акчалары | Бөтен чорда | - | - | - | - | Зәй муниципаль районы оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 7.3. | Хезмәтне саклау буенча вакытлы журналларга язылуны оештыру | Оешмалар (учреждениеләр) акчалары | Бөтен чорда | - | - | - | - | Зәй муниципаль районы оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 7.4. | Айлыклар, “Хезмәтне саклау” көннәре, хезмәтне саклау буенча квартал саен семинарлар үткәрү | Оешмалар (учреждениеләр) акчалары | Бөтен чорда | - | - | - | - | Зәй муниципаль районы оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 8. Дәвалау-профилактика һәм тернәкләндерү чаралары | | | | | | | | |
| 8.1. | Хезмәткәрләргә, шул исәптән зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартларында эшләүчеләргә медицина тикшерүе үткәрү | Оешмалар һәм учреждениеләр акчалары | Ел саен | - | - | - | - | Зәй муниципаль районы оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре (килешү буенча) |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 8.2. | Зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартларында эшләүчеләрне сөт һәм башка шуңа тиң кыйммәтле продуктлар белән тәэмин итү | Оешмалар һәм учреждениеләр акчалары | Бөтен чорда | - | - | - | - | Зәй муниципаль районы оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 8.3. | Медицина пунктлары өчен медикаментлар аптечкасы сатып алу | Оешмалар һәм учреждениеләр акчалары | Ел саен | - | - | - | - | Зәй муниципаль районы оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 8.4. | Медицина кабинеты өчен җиһазлар сатып алу | Оешмалар һәм учреждениеләр акчалары | Аерым планнар буенча | - | - | - | - | Зәй муниципаль районы оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 8.5 | Дәвалау-профилактика процедуралары бирүне оештыру | Оешмалар һәм учреждениеләр акчалары | Бөтен чорда | - | - | - | - | Зәй муниципаль районы оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 8.6. | Санатор-курорт юлламалары алу | Оешмалар һәм учреждениеләр акчалары | Ел саен | - | - | - | - | Зәй муниципаль районы оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 8.7. | Эш урынында имгәнү алган затларга матди ярдәм күрсәтү | Оешмалар һәм учреждениеләр акчалары | Бөтен чорда | - | - | - | - | Зәй муниципаль районы оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 8.8. | Хезмәтнең зарарлы һәм (яисә) куркыныч шартларында эшләүче хезмәткәрләр өчен дәвалау-профилактика туклануын тәэмин итү | Оешмалар һәм учреждениеләр акчалары | Бөтен чорда | - | - | - | - | Зәй муниципаль районы оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 9. Хезмәт шартларын махсус бәяләү үткәрү | | | | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 9.1. | Хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыруны тәэмин итү | Оешмалар һәм учреждениеләр акчалары | Бөтен чорда | - | - | - | - | Зәй муниципаль районы оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 9.2. | Җитештерү мохите факторларын инструменталь алмаштыруны тәэмин итү | Оешмалар һәм учреждениеләр акчалары | Аерым планнар һәм графиклар буенча | - | - | - | - | Зәй муниципаль районы оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 10. Хезмәткәрләрне саклау чаралары белән тәэмин итү | | | | | | | | |
| 10.1. | Махсус кием, махсус аяк киеме һәм башка индивидуаль һәм күмәк яклау чаралары белән тәэмин итү | Оешмалар һәм учреждениеләр акчалары | Бөтен чорда | - | - | - | - | Зәй муниципаль районы оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 10.2. | Махсус кием юуны оештыру | Оешмалар һәм учреждениеләр акчалары | Бөтен чорда | - | - | - | - | Зәй муниципаль районы оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 10.3. | Эшчеләрне нәтиҗәле юа торган һәм майсызландыра торган яңа средстволар белән тәэмин итү | Оешмалар һәм учреждениеләр акчалары | Бөтен чорда | - | - | - | - | Зәй муниципаль районы оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре (килешү буенча) |

Зәй муниципаль районында 2022-2024 елларга хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау муниципаль программасына 2 нче кушымта

## Программаның индикаторлары

| Максат исеме | Бурыч исеме | | Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның күрсәткечләре 2022 | 2023 | 2024 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Хезмәтне саклауга һәм хезмәт шартларына куркынычсызлык һәм гигиена таләпләренә җавап бирә торган конституция гарантияләрен тәэмин итү | 1. Хезмәтне саклауны хокукый һәм норматив тәэмин итү | 1.1. | Хезмәтне саклау өлкәсендә хокукый актларны камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү | Зәй муниципаль районы башкарма комитеты | 2022-2024 | 1000 эшчегә исәпләгәндә җитәкчеләр һәм белгечләрнең хезмәтне саклау буенча укулар узу күрсәткече - % | 100 | 100 | 100 |
| | | | | | | 1 кешегә исәпләгәндә, хезмәтне саклау чараларына чыгымнарны - 25.000 (сум) % | 100 | 100 | 100 |
| | | | | | | производствода бәхетсезлек очракларыннан зыян күргән кешеләр санын 1000 эшләүчегә исәпләгәндә - 1000 эшләүчегә 1.0 кешегә кадәр; | 1 | 1 | 1 |
| | | | | | | зыянлы һәм куркыныч хезмәт шартларында эшләүче хезмәткәрләрнең чагыштырма зурлыгын – 50.50гә кадәр; | 50 | 49 | 48 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2. Хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны оештыру һәм техник яктан тәэмин итү | 2.1.<br>2.2.<br>2.3.<br>2.4.<br>2.5.<br>2.6.<br>2.7.<br>2.8.<br>2.9<br>2.10 | - Хезмәтне саклау буенча норматив күрсәтмә документлар сатып алу һәм пропагандалау<br>- Россия Федерациясе Хезмәт Кодексының 217 статьясы нигезендә предприятиеләрдә хезмәтне саклау хезмәте булдыруны тәэмин итәргә.<br>- «Бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан хезмәткәрләрне мәҗбүри социаль иминләштерү турында " 1998 елның 24 июлендәге 125-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законын гамәлгә ашыру буенча чаралар эшләү (2013 елның 02 июлендә кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән)<br>- Хезмәтне саклау кабинетлары һәм почмакларын булдыру, аларны җиһазлау.<br>- Норматив срокларын эшләгән һәм хезмәтне саклау таләпләренә туры килми торган җиһазларны модернизацияләү, реконструкцияләү, эксплуатацияләүдән чыгару.<br>- Хезмәтне саклау һәм куркынычсыз хезмәт шартлары тәэмин итү буенча күрсәтмә әсбаплар белән тулыландыру.<br>- Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы хезмәтне саклау буенча координацион совет утырышларын үткәрү.<br>- Зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартларында эшләүче хатын-кызларның хезмәтен чикләү буенча чаралар эшләү.<br>- Массакүләм мәгълүмат чараларында Зәй муниципаль районы предприятиеләрендә хезмәт шартларының һәм хезмәтне саклауның торышы, эш урынында имгәнүләр һәм һөнәри авырулар торышын яктырту.<br>- Бөтендөнья хезмәтне саклау көне кысаларында чаралар әзерләү һәм үткәрү – 28 апрель. | | | 1000 эшчегә исәпләгәндә җитәкчеләр һәм белгечләрнең хезмәтне саклау буенча укулар узу күрсәткече - % | 100 | 100 | 100 |
| | | | | | | 1 кешегә исәпләгәндә, хезмәтне саклау чараларына чыгымнар - 25.000 (сум) % | 100 | 100 | 100 |
| | | | | | | 1000 эшчегә исәпләгәндә производствода бәхетсезлек очракларыннан зыян күргән кешеләр санын киметү – 1.0 гә кадәр | 1 | 1 | 1 |
| | | | | | | Зыянлы һәм куркыныч хезмәт шартларында эшләүче хезмәткәрләрнең чагыштырма зурлыгын – 50.50гә кадәр; | 50 | 49 | 48 |
| | 3. Хезмәтне саклау белән дәүләт | 3.1. | - Хезмәткәрләрне, шул исәптән оешма җитәкчеләрен, шулай ук эш бирүчеләрне, шәхси эшмәкәрләрне, хезмәтне саклау таләпләрен билгеләнгән тәртиптә укытуны оештыру, аларның | | | 1000 эшчегә исәпләгәндә җитәкчеләр һәм белгечләрнең хезмәтне саклау буенча укулар узу күрсәткече - % | 100 | 100 | 100 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | идарәсе системасын үстерү | | хезмәтне саклау таләпләрен белүләрен тикшерү, шулай ук производствода зыян күрүчеләргә беренче ярдәм күрсәтү буенча укулар үткәрү, хезмәтне саклау буенча инструктаж үткәрү, эш урынында стажировка үткәрү. | | | 1 кешегә исәпләгәндә, хезмәтне саклау чараларына чыгымнар - 25.000 (сум) % | 100 | 100 | 100 |
| | | 3.2. | - Хезмәт шартлары буенча хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрүне оештыру һәм хезмәтне саклау буенча эшләрне оештыруның хезмәтне саклау буенча дәүләт норматив таләпләренә туры килүен раслау. | | | 1000 эшчегә исәпләгәндә производствода бәхетсезлек очракларыннан зыян күргән кешеләр санын киметү – 1.0 гә кадәр; | 1 | 1 | 1 |
| | | 3.3. | - Район территориясендә эшчәнлек алып баручы эш бирүчеләрдән хезмәт шартларының һәм хезмәтне саклауның торышы турында мәгълүмат җыю һәм эшкәртүне оештыру. | | | Зыянлы һәм куркыныч хезмәт шартларында эшләүче хезмәткәрләрнең чагыштырма зурлыгын – 50.50гә кадәр; | 50 | 49 | 48 |
| | | 3.4. | - Зәй муниципаль районы предприятиеләрендә, оешмаларында, учреждениеләрендә производство травмалары, һөнәри авырулар торышы мониторингын гамәлгә ашыру. | | | | | | |
| | | 3.5. | - Зәй МР предприятиеләрендә хезмәтне саклауның торышы, производство травмалары, һөнәри авырулар турында аналитик белешмә әзерләү. | | | | | | |
| | | 3.6. | - Зәй муниципаль районы предприятиеләрендә, оешмаларында һәм оешмаларында хезмәт шартларының һәм хезмәтне саклауның торышы буенча уртак комплекслы тикшерүләр үткәрүдә катнашу. | | | | | | |
| | 4. Дәвалау-профилактика һәм терәкләндерү чаралары | 4.1. | - РФ Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2011 елның 12 апрелендәге 302н номерлы боерыгы нигезендә, хезмәткәрләргә башлангыч һәм вакытлы медицина тикшерүләре үткәрүне оештыру | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 5. Предприятиеләрдә хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау | 5.1.<br>5.2.<br>5.3. | - ЗМР ның һәр предприятиесе (учреждениесе) буенча 2022-2024 елларга хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау программаларын эшләргә.<br>- Хатын-кыз хезмәте өстенлек иткән һәм 18 яшькә кадәрге затларның хезмәтен куллану белән бәйле предприятиеләрдә хезмәтне саклау турында законнар үтәлеше мәсьәләре буенча комплекслы максатчан тикшерүләр үткәрүдә катнашу.<br>- Хатын-кызлар өчен гигиена һәм көнкүреш бүлмәләрен ремонтлау һәм җиһазлау. | | | 1000 эшчегә исәпләгәндә җитәкчеләр һәм белгечләрнең хезмәтне саклау буенча укулар узу күрсәткече - % | 100 | 100 | 100 |
| | | | | | | 1 кешегә исәпләгәндә, хезмәтне саклау чараларына чыгымнар - 25.000 (сум) % | 100 | 100 | 100 |
| | | | | | | 1000 эшчегә исәпләгәндә производствода бәхетсезлек очракларыннан зыян күргән кешеләр санын киметү – 1.0 гә кадәр; | 1 | 1 | 1 |
| | | | | | | Зыянлы һәм куркыныч хезмәт шартларында эшләүче хезмәткәрләрнең чагыштырма зурлыгын – 50.50гә кадәр; | 50 | 49 | 48 |
| | 6. Хезмәтне саклау өлкәсендә социаль партнерлыкны камилләштерү | 6.1. | Оешмаларда һәм учреждениеләрдә хезмәтне саклау буенча күмәк шартнамәләр һәм чаралар планнары проектларын әзерләүне методик һәм оештыру ягыннан тәэмин итү. | | | 1000 эшчегә исәпләгәндә җитәкчеләр һәм белгечләрнең хезмәтне саклау буенча укулар узу күрсәткече - % | 100 | 100 | 100 |
| | | | | | | 1 кешегә исәпләгәндә, хезмәтне саклау чараларына чыгымнар - 25.000 (сум) % | 100 | 100 | 100 |
| | | | | | | 1000 эшчегә исәпләгәндә производствода бәхетсезлек очракларыннан зыян күргән кешеләр санын киметү – 1.0 гә кадәр; | 1 | 1 | 1 |
| | | | | | | Зыянлы һәм куркыныч хезмәт шартларында эшләүче хезмәткәрләрнең чагыштырма зурлыгын – 50.50гә кадәр; | 50 | 49 | 48 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 7. Хезмәтне саклау, мәгълүмати тәэмин итү һәм хезмәтне саклауны пропагандалау мәсьәләләре буенча хезмәткәрләрне, җитәкчеләрне һәм белгечләрне укыту | 7.1<br>7.2.<br>7.3.<br>7.4. | Хезмәтне саклау буенча җитәкчеләр, хезмәтне саклау белгечләренең укуларын оештыру.<br>Хезмәтне саклау буенча норматив күрсәтмә документлар, махсус әдәбият, уку һәм күрсәтмә әсбаплар сатып алу.<br>Хезмәтне саклау буенча периодик журналларга язылуны оештыру.<br>Хезмәтне саклау айлыклары, «Хезмәтне саклау» көннәре, хезмәтне саклау буенча квартал саен семинарлар үткәрү. | | | 1000 эшчегә исәпләгәндә җитәкчеләр һәм белгечләрнең хезмәтне саклау буенча укулар узу күрсәткече - % | 100 | 100 | 100 |
| | | | | | | 1 кешегә исәпләгәндә, хезмәтне саклау чараларына чыгымнар - 25.000 (сум) % | 100 | 100 | 100 |
| | | | | | | 1000 эшчегә исәпләгәндә производствода бәхетсезлек очракларыннан зыян күргән кешеләр санын киметү – 1.0 гә кадәр; | 1 | 1 | 1 |
| | | | | | | Зыянлы һәм куркыныч хезмәт шартларында эшләүче хезмәткәрләрнең чагыштырма зурлыгын – 50.50гә кадәр; | 50 | 49 | 48 |
| | 8. Дәвалау-профилактика һәм тернәкләндерү чаралары | 8.1.<br>8.2.<br>8.3.<br>8.4.<br>8.5. | Зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартларында эшләүче хезмәткәрләргә мәҗбүри медицина тикшерүләре уздыру.<br>Зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартларында эшләүчеләрне сөт һәм башка шуңа тиңләштерелгән продуктлар белән тәэмин итү<br>Медпунктлар өчен аптечкалар, медикаментлар сатып алу.<br>Медицина кабинеты өчен җиһазлар сатып алу.<br>Дәвалау-профилактика процедураларын күрсәтүне | | | 1000 эшчегә исәпләгәндә җитәкчеләр һәм белгечләрнең хезмәтне саклау буенча укулар узу күрсәткече - % | 100 | 100 | 100 |
| | | | | | | 1 кешегә исәпләгәндә, хезмәтне саклау чараларына чыгымнар - 25.000 (сум) % | 100 | 100 | 100 |
| | | | | | | 1000 эшчегә исәпләгәндә производствода бәхетсезлек очракларыннан зыян күргән кешеләр санын киметү – 1.0 гә кадәр; | 1 | 1 | 1 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | оештыру.<br><br>Шифаханә-курорт юлламалары алу.<br><br>Эш урыныда имгәнү алган затларга матди ярдәм күрсәтү.<br><br>Зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартларында эшләүче хезмәткәрләр өчен дәвалау-профилактика туклануын тәэмин итү. | | | Зыянлы һәм куркыныч хезмәт шартларында эшләүче хезмәткәрләрнең чагыштырма зурлыгын – 50.50гә кадәр; | 50 | 49 | 48 |
| | 9. Хезмәт шартларын махсус бәяләү үткәрү | 9.1.<br><br>9.2 | Хезмәт шартларын махсус бәяләү үткәрүне тәэмин итү.<br><br>Җитештерү тирәлеге факторларын инструменталь үлчәү үткәрүне тәэмин итү. | | | 1000 эшчегә исәпләгәндә җитәкчеләр һәм белгечләрнең хезмәтне саклау буенча укулар узу күрсәткече - % | 100 | 100 | 100 |
| | | | | | | 1 кешегә исәпләгәндә, хезмәтне саклау чараларына чыгымнар - 25.000 (сум) % | 100 | 100 | 100 |
| | | | | | | 1000 эшчегә исәпләгәндә производствода бәхетсезлек очракларыннан зыян күргән кешеләр санын киметү – 1.0 гә кадәр; | 1 | 1 | 1 |
| | | | | | | Зыянлы һәм куркыныч хезмәт шартларында эшләүче хезмәткәрләрнең чагыштырма зурлыгын – 50.50гә кадәр; | 50 | 49 | 48 |
| | 10. Хезмәткәрләрне саклану | 10.1 | Эшчеләрне махсус кием, махсус аяк киеме һәм башка шәхси һәм күмәк саклану чаралары белән тәэмин итү. | | | 1000 эшчегә исәпләгәндә җитәкчеләр һәм белгечләрнең хезмәтне саклау буенча укулар узу күрсәткече - % | 100 | 100 | 100 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | чаралары белән тәэмин итү | 10.2<br>10.3 | Махсус эш киемнәрен юу эшен оештыру.<br>Эшчеләрне яңа эффеклы юдыру һәм майсызландыру чаралары белән тәэмин итү | | | 1 кешегә исәпләгәндә, хезмәтне саклау чараларына чыгымнар - 25.000 (сум) % | 100 | 100 | 100 |
| | | | | | | 1000 эшчегә исәпләгәндә производствода бәхетсезлек очракларыннан зыян күргән кешеләр санын киметү – 1.0 гә кадәр; | 1 | 1 | 1 |
| | | | | | | Зыянлы һәм куркыныч хезмәт шартларында эшләүче хезмәткәрләрнең чагыштырма зурлыгын – 50.50гә кадәр; | 50 | 49 | 48 |

Искәрмә: Индикаторларның күрсәткече бурычлар буенча китерелгән.

Һәр чараны индикаторлар белән бәяләү мөмкин түгел, чөнки программа тарафыннан куелган максатка бары тик барлык чараларны комплекслы гамәлгә ашырганда гына ирешелә.